# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

"21" ноябрь 2020 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 21 ноябрендә «Сез 2021 елда Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- җирле автомобиль юлларында юл эшләре өчен: Иске Мәңгәр авылында юлларны төзекләндерү һәм төзү өчен хезмәтләргә түләү, төзелеш материаллары алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 169 (йөз алтмыш тугыз) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 101 (йөз дә бер) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 101 (йөз дә берт) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. "Сез 2021 елда Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме: - җирле автомобиль юлларында юл эшләре өчен: Иске Мәңгәр авылында юлларны төзекләндерү һәм төзү өчен хезмәтләргә түләү, төзелеш материаллары алу" мәсьәләсен кабул итәргә.
3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы Тахавиев Ф.К.